ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2020 п.г.т. Алексеевское № 5

**Инвалидлар эшләре буенча**
**Совет төзү турында**

Инвалидларны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарә органнары белән иҗтимагый оешмалар арасындагы хезмәттәшлекне координацияләү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 2 декабрендәге Инвалидлар эшләре советы утырышы йомгаклары буенча йөкләмәләре исемлеген үтәү максатларында

**карар кылам:**

1. Алексеевск муниципаль районында инвалидлар эшләре буенча Совет төзергә.

2. Алексеевск муниципаль районындагы инвалидлар эшләре буенча совет турындагы Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

3. Алексеевск муниципаль районындагы инвалидлар эшләре советы составын расларга (2 нче кушымта).

4. «Инвалидлар эшләре буенча Совет төзү турында» 2012 елның 23 маендагы 20 нче номерлы Алексеевск муниципаль районы башлыгы карары югалган дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Н. К. Кадыйровка йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы** **С.А.Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы башлыгының
22.01.2020 5 нче номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Алексеевск районының инвалидлар эшләре буенча Советы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районының инвалидлар эшләре советы инвалидларны социаль яклау һәм тернәкләндерү өлкәсендә җирле үзидарә органнары, инвалидларның иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген координацияләү максатларында төзелә.

1.2.Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Совет составы Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана. Совет рәисе - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

1.4.Совет әгъзалары булып социаль яклау бүлеге, Пенсия фонды, Үзәк район хастаханәсе, Социаль иминият фонды, Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге вәкилләре, шулай ук инвалидларның иҗтимагый оешмасы вәкилләре тора.

## 2. Совет эшчәнлегенең төп максатлары һәм бурычлары

2.1.Совет эшчәнлегенең максаты - республика һәм район максатчан программалары нигезендә уздырыла торган инвалидларны социаль яклау һәм реабилитацияләү чараларының нәтиҗәлелеген арттыру.

2.2. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- район территориясендә инвалидларны нәтиҗәле реабилитацияләү һәм аларның җәмгыятькә интеграциясе өчен шартлар тудыру;
- социаль яклау, сәламәтлек саклау, мәгариф, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте учреждениеләренә, реабилитация чараларын гамәлгә ашыручы башка оешмаларга инвалидлар белән эшләүне камилләштерүгә ярдәм итү;
- инвалидларны матди тәэмин итү һәм социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итү;

- инвалидларның социаль инфраструктура объектларына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү;
- инвалидларга тулы күләмдә ял итү, спорт белән актив шөгыльләнү, иҗади потенциалны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.

2.3. Куелган максатка ирешү һәм югарыда санап үтелгән бурычлар нигезендә Совет түбәндәге функцияләрне башкара:
- инвалидлар белән проблемалар буенча район программаларын эшләүдә катнаша, анализлый, аны үтәү барышын коррекцияли, әлеге программаны гамәлгә ашыру буенча киңәшләр эшли;
- Алексеевск муниципаль районы Советына инвалидларның хәле һәм инвалидлык проблемалары турында аналитик докладлар бирә, Совет эшчәнлеге өлкәсенә керүче мәсьәләләр буенча район башлыгына тәкъдимнәр кертә;
- инвалидлар проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен җирле үзидарә органнары, оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләүне таләп итә торган мәсьәләләрне карый;
- районда инвалидларның реаль хәлен ачыклау һәм аларны социаль яклауны яхшырту чараларын эшләү максатларында тикшеренүләр үткәрүгә ярдәм итә, шулай ук инвалидлар белән эшләүнең алдынгы тәҗрибәсен таратуда һәм гамәлгә кертүдә ярдәм итә;
- Совет бурычларыннан килеп чыга торган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

## 3. Совет эшен оештыру

3.1.Совет утырышлары кирәк саен, ярты елга кимендә 1 тапкыр уздырыла. Чираттагы утырышның датасы, уздыру урыны һәм көн тәртибе турында Совет әгъзалары аны уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш. Совет әгъзасы нинди дә булса сәбәпләр аркасында утырышта катнаша алмаса, ул бу турыда Совет секретарена хәбәр итәргә тиеш.

3.2.Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы булып санала. Совет карарлары Советның утырышта катнашучы әгъзалары санынннан гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Совет кабул иткән карарлар рекомендация характерында.

3.3. Совет утырышына җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, гражданнарның иҗтимагый берләшмәләре җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары, массакүләм мәгълүмат чаралары чакырылырга мөмкин.

## 4. Совет хокуклары

Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен совет түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1. Җирле үзидарә органнарыннан Совет компетенциясе чикләрендә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат соратып алырга.

4.2. Эксперт һәм аналитик эшләр башкару өчен Совет утырышларына материаллар әзерләү өчен эш төркемнәре булдырырга.

4.3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре советы утырышларында Россия Федерациясе законнарын һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру турында тыңларга.

4.4.Эшләргә һәм район Советы каравына инвалидларны социаль яклауның нәтиҗәлелеген арттыру һәм тернәкләндерүнең нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен кертергә.

**Совет Аппараты җитәкчесе** **А.С.Харитонов**

Алексеевск муниципаль
районы башлыгының
22.01.2020 5 нче номерлы
2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районының
инвалидлар эшләре Советы
составы**

1. Кадыйров Н.К. - Башкарма комитет җитәкчесе, Совет рәисе

2. Чурин Н.П. - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Совет рәисе урынбасары

3. Семина Н.А. - ТР МТЗиСЗ «Радуга» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры (килешү буенча)

Совет әгъзалары:

4. Абакумов А.Н. - Инфраструктур үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары

5. Тимонина Н.Ю. - Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры (килешү буенча)

6. Фасахова А.Р - "Алексеевск үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибы урынбасары (килешү буенча)

7. Гордеев Н.М. - Алексеевск районы Әфганстан инвалидларының иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)

8. Седова Н.К. - Алексеевск районы инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча)

9. Сөләйманов Р.Б. - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы

10. Соловьев А.Г. - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният бүлеге башлыгы

11. Хамзина Е.А. - Халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)

12. Салюков Е.Г. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы

**Совет Аппараты**
**Җитәкчесе** **А.С.Харитонов**